**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**БИЕКТАУ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КАЗАКЛАР АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422722, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Казаклар авылы, Совет ур., 5

**СОВЕТ КАЗАКЛАРСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ВЫСОКОГОРСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422722, Республика Татарстан, Высокогорский район
с. Казаклар, ул. Советская, 5

Тел./факс: +7(84365) 63-4-30, e-mail: Kazak.Vsg@tatar.ru

---

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**27 август 2020 г.** **№154**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлеге торак пунктларының урамнарына һәм башка состав өлешләренә исемнәр бирү, исемнәрен үзгәртү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, 2003 нче елның 6 нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон нигезендә, “Биектау муниципаль районының Казаклар авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Казаклар авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Кушымтада китерелгән Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлеге торак пунктларының урамнарына һәм башка состав өлешләренә исемнәр бирү, исемнәрен үзгәртү тәртибе турындагы Нигезләмәне расларга.
2. Әлеге карарны Биектау муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адресы һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ буенча урнаштырып халыкка җиткерергә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам**.**

Совета рәисе
Авыл җирлеге Башлыгы Р.Х.Идрисов

Кушымта

Расланды

Биектау муниципаль районының Казаклар авыл җирлеге Советының 2020 нче елның __________ N __

Карары белән

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлеге торак пунктларының урамнарына һәм башка состав өлешләренә исемнәр бирү, исемнәрен үзгәртү тәртибе турындагы Нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлеге торак пунктларының урамнарына һәм башка состав өлешләренә исемнәр бирү, исемнәрен үзгәртү тәртибе турындагы әлеге Нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) 2003 нче елның 6 нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, "Биектау муниципаль районының Казаклар авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә эшләнде һәм Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлеге торак пунктларының урамнарына һәм башка состав өлешләренә исемнәр бирү, исемнәрен үзгәртүнең бердәм тәртибен тәэмин итүнең хокукый нигезләрен билгели.

1.2. "Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлеге торак пунктларының урамнарына һәм башка состав өлешләренә исемнәр бирү, исемнәрен үзгәртү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау турында" карары Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлеге Советы тарафыннан кабул ителә.

1.3. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлегенең урамнары һәм башка состав өлешләренең исемнәрен бирүгә куела торган төп таләпләр:

- территориянең тиешле өлешенең географик, тарихи, шәһәр төзелеше һәм башка үзенчәлекләренә туры килергә тиеш;
- урамның һәм территориянең башка состав өлешләренең иң мөһим индивидуаль характеристикаларын чагылдырырга;
- әйтелү өчен уңай һәм матур яңгырашлы булырга тиеш;
- Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дөрес язылыш һәм әйтелешнең әдәби нормаларына туры килергә;
- яңа исемнәр гамәлдәге исемнәрне кабатларга тиеш түгел.

1.4. Исемнәрне бирү Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлегенең яңа барлыкка килгән урамнарына, мәйданнарына, торак пунктларының башка состав өлешләренә, шулай ук аларның исемнәрен үзгәрткәндә башкарыла.

1.5. Өстенлек Татарстан Республикасы халкының милли тарихын, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен чагылдыручы атамаларга бирелә.

1.6. Бер исемнәрне икенчеләре белән алмаштыру, бозылган исемнәрне куллану рөхсәт ителми.

## 2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлеге торак пунктларының урамнарына һәм башка состав өлешләренә исемнәр бирү, исемнәрен үзгәртү турында тәкъдимнәр кертү тәртибе

2.1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлеге торак пунктларының урамнарына һәм башка состав өлешләренә исемнәр бирү, исемнәрен үзгәртү әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә түбәндәгеләрнең тәкъдимнәре буенча гамәлгә ашырыла:

- дәүләт хакимияте органнары;
- җирле үзидарә органнары;
- дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр;
- җәмәгать оешмалары;
- Казаклар авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган Россия Федерациясе гражданнары. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлегенең торак пунктларының урамнарына һәм башка состав өлешләренә исемнәр бирү, исемнәрен үзгәртү буенча гражданнарның инициативасы кимендә 30 (утыз) кешедән торган инициативалы төркем төзү юлы белән гамәлгә ашырыла;
- Казаклар авыл җирлеге территориясендә билгеләнгән тәртиптә теркәлгән һәм эшчәнлек алып баручы юридик затлар.

2.2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлеге торак пунктларының урамнарына һәм башка состав өлешләренә исемнәр бирү турында тәкъдимнәр Казаклар авыл җирлеге Советына әлеге Нигезләмәнең 2.1.пунктында күрсәтелгән затлар (алга таба – инициаторлар) тарафыннан язма рәвештә кертелә.

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлеге торак пунктларының урамнарына һәм башка состав өлешләренең исемнәрен үзгәртү турында тәкъдимнәр Казаклар авыл җирлеге Башлыгы исеменә әлеге Нигезләмәнең 2.1.пунктында күрсәтелгән затлар (алга таба – инициаторлар) тарафыннан язма рәвештә кертелә.

2.3. Исемнәр бирү, исемнәрен үзгәртү инициаторлары тарафыннан түбәндәге документлар тапшырыла:

- Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлеге торак пунктларының урамнарына һәм башка состав өлешләренә исемнәр бирү, исемнәрен үзгәртү турында үтенеч;
- тәкъдим ителә торган исемнең географик һәм тарихи-мәдәни нигезләмәсе;
- атаклы кешеләр истәлеген мәңгеләштергәндә, тасвирлана торган вакыйгаларны, аларның тормышы, эшчәнлеге турындагы биографик мәгълүматларны раслый торган документлар теркәлә һәм аларның казанышлары, шулай ук аларның мирасы хокукына ия булган гаиләсе һәм туганнарының ризалыгы күрсәтелә (алар булган очракта);
- имза кәгазе, үтенеч белән әлеге Нигезләмәгә кушымта нигезендә рәсмиләштерелгән инициативалы төркем мөрәҗәгать иткән очракта.

Имза кәгазендә инициативалы төркем әгъзалары үз куллары белән үзләренең фамилияләрен, исемен һәм атасының исемен, шәхесен таныклаучы документ күрсәткечләрен (шәхесне таныклый торган документның сериясен, номерын, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгәнен), яшәү урыны адресын күрсәтәләр, үз имзаларын һәм аны кую датасын күрсәтәләр. Имзалар кәгазе имзалар җыюны гамәлгә ашыручы инициативалы төркем әгъзасы тарафыннан таныклана.

2.4. Үтенечтә түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

- фаразланган исем;

- Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлеге торак пунктларының урамнары һәм башка состав өлешләренең урнашуы күрсәтелгән карта-схема.

- Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлеге торак пунктларының урамнарына һәм башка состав өлешләренә исемнәр бирү, исемнәрен үзгәртү турында тәкъдим керткән инициаторлар турында белешмәләр, аларның адреслары, телефоннары.

## 3. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлеге торак пунктларының урамнарына һәм башка состав өлешләренә исемнәр бирү тәртибе

3.1. Тәкъдимнәрне карау нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлеге торак пунктларының урамнарына һәм башка состав өлешләренә исемнәр белән килешкән очракта, Казаклар авыл җирлеге Советы Казаклар авыл җирлеге торак пунктларының урамнарына һәм башка состав өлешләренә исемнәр бирү турында карар кабул итә.

3.2. Казаклар авыл җирлеге торак пунктларының урамнарына һәм башка состав өлешләренә исемнәр белән килешмәгән очракта, Казаклар авыл җирлеге Советы Казаклар авыл җирлегенең торак пунктларының урамнарына һәм башка состав өлешләренә исемнәр бирүнең максатка ярашлы булмавы турында карар кабул итә һәм өч көн эчендә Казаклар авыл җирлегенең торак пунктларының урамнарына һәм башка состав өлешләренә исемнәр бирүдән баш тарту турында инициаторларга язма белдерү җибәрелә.

## 4. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлеге торак пунктларының урамнарына һәм башка состав өлешләренең исемнәрен үзгәртү тәртибе

4.1. Тәкъдимнәрне карау нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлеге торак пунктларының урамнары һәм башка состав өлешләре исемнәрен үзгәртү белән килешкән очракта, Казаклар авыл җирлеге Башлыгы карары белән исемнәрен үзгәртергә планлаштырылган Казаклар авыл җирлегенең торак пунктларының урамнарында яисә башка состав өлешләрендә яшәүчеләрнең фикерен ачыклау максатыннан тәкъдимнәр кергән вакыттан ун көн эчендә халык алдында тыңлаулар билгеләнә.

4.2. Казаклар авыл җирлеге торак пунктларының урамнары һәм башка состав өлешләре исемнәрен үзгәртү белән килешмәгәндә, Казаклар авыл җирлеге Башлыгы

өч көн эчендә Казаклар авыл җирлегенең торак пунктларының урамнарына һәм башка состав өлешләренә исемнәр бирүдән баш тарту турында инициаторларга язма белдерү җибәрелә.

Халык алдында тыңлаулар нәтиҗәләре буенча халыкка җиткерелергә тиешле бәяләмә чыгарыла.

4.3. Халык Казаклар авыл җирлеге торак пунктларының урамнарын, яки башка состав өлешләренең исемнәрен үзгәртү турындагы тәкъдим белән килешкәндә, Казаклар авыл җирлеге Башлыгы Казаклар авыл җирлеге Советына Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлегенең торак пунктлары урамнарын үзгәртү турындагы Советның Карар проектын раслау өчен юллана. Казаклар авыл җирлеге Советы якындагы утырышта Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлегенең торак пунктлары урамнары исемнәрен үзгәртү турында карар кабул итә.

4.4. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлегенең торак пунктлары урамнары исемнәрен үзгәртү турындагы тәкъдим белән халык риза булмаган очракта, Казаклар авыл җирлеге Башлыгы Казаклар авыл җирлеге торак пунктларының урамнары һәм башка состав өлешләренең исемнәрен үзгәртүнең максатка ярашлы булмавы турында карар кабул итә һәм ун көн эчендә мондый баш тарту турында инициаторларга язма рәвештә хәбәр итә.

## 5. Йомгаклау нигезләмәләре

5.1. Әлеге Нигезләмә белән җайга салынмаган мәсьәләләр гамәлдәге законнар нигезендә билгеләнә.

5.2. Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлегенең торак пунктларының урамнары һәм башка состав өлешләре исемнәрен язу аларны Казаклар авыл җирлеге Советы карарында билгеләнүе белән катгый рәвештә туры китереп башкарыла.

Кушымта
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлеге торак пунктлары урамнарына

һәм башка состав өлешләренә исемнәр бирү, исемнәрен үзгәртү тәртибе турындагы Нигезләмәгә

**ИМЗАЛАУ КӘГАЗЕ**

Без, түбәндә имза куйган гражданнарның ициативалы төркеме әгъзалары, ________________________________,урнашкан _________________________________________ исемендәге объектка түбәндәге исемне бирергә тәкъдим итәбез __________________________________________________________________________,

| Т/б N | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Паспорт яки аны алыштыручы башка документ күрсәткечләре | Адрес | Имза | Дата |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |